СОВЕТ ШУБАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШУБАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» сентябрь 2018 ел № 78

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча жирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Шубан авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, Шубан авыл җирлеге Советының 2018 елның №77 «Шубан авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын, Шубан авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 18 сентябрендәге «Шубан авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында " гы 7 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга: "2019 елда Шубан авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:
- Югары Шубан авылында: Центральная урамында уен мәйданчыгы урнаштыру өчен җир участогын рәсмиләштерү,балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру; Центральная һәм Молодежная урамында юл ремонтлау.;
- Түбән Шубан авылында: Г.Тукай урамын ремонтлау;
- Зур Лызи 2 өлеш авылында балалар уен мөйданчыгы сатып алу,зиратта ретуаль хезмәтләр инвентарьләрен саклау өчен будка төзү;
- Ярак-Чурма авылында:М.Горький хэм Мира урамнарына 3 янгынга каршы гидрантлар һәм аларга комплектлау әйберләре сатып алу;
- Гондыр авылында: Советская урамына янгынга каршы гидрант һәм ана

комплектлау әйберләре сатып алу
Әйе ЮК"

3. Шубан авыл җирлеге Советы карары нигезендә, аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаны экономияләү очрагында, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.
4. Әлеге карарны " Хезмәт» район газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга pravo.tatarstan.ru-авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка хәбәр итәргә, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга кирәк baltasi.tatarstan.ru к
5. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Мөҗипов.